| 4 нче ярдәмче программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасы территориясендә су мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру.<br>2. Инженерлык саклау корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү.<br>3. Гидротехника корылмаларының эксплуатацияләү ышанычлылыгын аларны куркынычсыз техник хәлгә китерү юлы белән арттыру.<br>4. Елгаларның үткәрү сәләтен арттыру максаты белән аларның юлларын турайту һәм чистарту.<br>5. Су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү. |
| 4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2014 – 2021 еллар |

<table>
<tr>
<td>4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 300 260,5 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән 1 623 824,3 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 676 436,1 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Акча, барлыгы</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>599 184,9</td><td>508 372,8</td><td>90 812,1</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>153 356,8</td><td>94 927,8</td><td>58 429,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>187 233,9</td><td>116 112,9</td><td>71 121,0</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 013 376,8</td><td>710 467,9</td><td>302 908,9</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>231 812,6</td><td>181 317,9</td><td>50 494,7</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>58 471,2</td><td>12 625,0</td><td>45 846,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>28 412,1</td><td>-</td><td>28 412,1</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>28 412,1</td><td>-</td><td>28 412,1</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 300 260,5</td><td>1 623 824,4</td><td>676 436,1</td></tr>
</table>
*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td>
</tr>
<tr>
<td>Еллар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2017 елга:<br>инженерлык саклавының һәм ярны ныгытуның төзекләндерелгән яңа корылмалары озынлыгын 12,98 километрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү эшләре озынлыгын 6,48 километрга кадәр арттырырга;<br>2018 елга:<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә экологик яшәү шартлары яхшыртылачак халык санын 260,1 мең кешегә арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә су төбендәге утырмалар уентысы күләмен 276,0 мең куб.метрга кадәр арттырырга;<br>су объектларын торгызу һәм экологик тернәкләндерү эшләре мәйданын 681,1 мең кв.метрга кадәр арттырырга;<br>2019 елга:<br>суның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче яшәүче халыкның гомуми санында әлеге</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | территорияләрдә яшәүче, суларның тискәре йогынтысыннан саклауны арттыру буенча чаралар үткәрү нәтиҗәсендә сакланылган халык өлешен 69,3 процентка кадәр арттырырга;<br>куркынычсызлыгы канәгатьләндерми һәм куркыныч дәрәҗәдә булган, куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары санын 58 берәмлеккә арттырырга;<br>куркынычсызлыгы канәгатьләндерми һәм куркыныч дәрәҗәдә булган гидротехника корылмаларының гомуми санында куркынычсыз техник хәлгә китерелгән гидротехника корылмалары өлешен 42 процентка кадәр арттырырга;<br>2021 елга:<br>су объектларыннан файдалану хокукларын судан файдалануны гамәлгә ашыру өчен сатып алуны күздә тоткан куллланучыларның гомуми санында билгеләнгән тәртиптә бирелгән файдалану хокуклары нигезендә су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыручы су кулланучылар өлешен 99 процентка кадәр арттырырга;<br>федераль милектәге су объектларыннан файдалану өчен түләү суммаларының расланган план мәгънәләренә карата су объектларыннан файдалану өчен түләү суммаларының Россия Федерациясе бюджет системасына фактта керү күләме чагыштырмасын 94 проценттан ким булмаган дәрәҗәдә сакларга;<br>су алу корылмаларының гомуми санында суны исәпкә алу системалары белән җиһазландырылган су алу корылмалары өлешен 96 процентка кадәр арттырырга»; |

II бүлектә:

илле беренче абзацта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 300 260,5 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән 1 623 824,4 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 676 436,1 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 599 184,9 | 508 372,8 | 90 812,1 |
| 2015 | 153 356,8 | 94 927,8 | 58 429,0 |
| 2016 | 187 233,9 | 116 112,9 | 71 121,0 |
| 2017 | 1 013 376,8 | 710 467,9 | 302 908,9 |
| 2018 | 231 812,6 | 181 317,9 | 50 494,7 |
| 2019 | 58 471,2 | 12 625,0 | 45 846,2 |
| 2020 | 28 412,1 | - | 28 412,1 |
| 2021 | 28 412,1 | - | 28 412,1 |
| Барлыгы | 2 300 260,5 | 1 623 824,4 | 676 436,1 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

4 нче ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының биологик төрлелеген саклау» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программа исемендә «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга:

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының биологик төрлелеген саклау» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа) |
| 5 нче ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (2014 – 2017 еллар), Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (2018 – 2021 еллар) |
| 5 нче ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасының биологик төрлелеген торгызу һәм саклау |

<table>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаның бурычлары</td><td>1. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре системасы белән дәүләт идарәсе, шул исәптән дәүләт табигать тыюлыклары эшчәнлеген норматив-хокукый, финанс-икътисадый, кадрлар белән тәэмин итү;<br>2. Табигать комплексларын һәм объектларын саклауны һәм яклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләрендә табигать байлыкларыннан файдалануны җайга салу;<br>3. Махсус саклана торган табигать территорияләре өлкәсендә экологик аң белем бирү һәм мәгълүмати-пропаганда эшчәнлеген гамәлгә ашыру</td></tr>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары</td><td>2014 – 2021 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 191 799,1 мең сум* тәшкил итә.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Барлык акча</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>24 648,6</td><td>24 648,6</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>23 958,4</td><td>23 958,4</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>23 992,7</td><td>23 992,7</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>21 767,8</td><td>21 767,8</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>33 386,6</td><td>33 386,6</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>20 732,5</td><td>20 732,5</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>21 342,5</td><td>21 342,5</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>21 970,0</td><td>21 970,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>191 799,1</td><td>191 799,1</td></tr>
</table>
* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр</td><td>5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру 2021 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>барлык дәрәҗәләрдәге МСТТ урнашкан Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 5,66 процентка кадәр арттырырга;<br>төбәк һәм җирле әһәмияттәге МСТТ урнашкан Татарстан Республикасы мәйданы өлешен 5,06 процентка кадәр</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | арттырырга;<br>Татарстан Республикасының МСТТдә билгеле булган һәм бетерелгән бозулар санын 670 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына ел саен кертелә торган төрләр санын 1 берәмлек дәрәҗәсендә сакларга;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, тагын да «түбән» сирәклек категориясенә күчерелгән төрләрнең еллык санын 1 берәмлек дәрәҗәсендә сакларга;<br>Татарстан Республикасының Кызыл китабыннан ел саен 1 төр чыгарырга;<br>МСТТ мәсьәләләре буенча лекцияләргә һәм башка гавами чараларга 22 мең укучыга кадәр җәлеп итәргә»; |

II бүлектә:
утыз сигезенче абзацта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;
III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 5 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 191 799,1 мең сум* тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 24 648,6 | 24 648,6 |
| 2015 | 23 958,4 | 23 958,4 |
| 2016 | 23 992,7 | 23 992,7 |
| 2017 | 21 767,8 | 21 767,8 |
| 2018 | 33 386,6 | 33 386,6 |
| 2019 | 20 732,5 | 20 732,5 |
| 2020 | 21 342,5 | 21 342,5 |
| 2021 | 21 970,0 | 21 970,0 |
| Барлыгы | 191 799,1 | 191 799,1 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

5 нче ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының аучылык ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа исемендә «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>«Ярдәмче программа исеме</td><td>«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының аучылык ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа)</td></tr>
<tr><td>6 нчы ярдәмче программаның дәүләт заказчысы</td><td>Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясын саклау һәм алардан файдалану идарәсе;<br>«Хайваннар дөньясын саклау өлкәсендә инновацион технологияләр кертү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе</td></tr>
<tr><td>6 нчы ярдәмче программаның максаты</td><td>Татарстан Республикасының аучылык ресурсларын саклау, торгызу һәм алардан рациональ файдалану</td></tr>
<tr><td>6 нчы ярдәмче программаның бурычлары</td><td>1. Аучылык ресурсларын торгызу өлкәсендә мәгълүмати-аналитик тәэмин итү;<br>2. Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга һәм аларны саклауга дәүләт күзәтчелеген тәэмин итү;<br>3. Дәүләт тәҗрибә аучылык хуҗалыкларында һәм су биологик ресурсларында аучылык ресурсларын саклауны һәм торгызуны тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>6 нчы ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары</td><td>2014 – 2021 еллар</td></tr>
<tr><td>6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 437 007,0 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән 285 879,3 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 151 127,7 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><td>Еллар</td><td>Акча, барлыгы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td><td>Федераль бюджет акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>63 899,9</td><td>45 601,8</td><td>18 298,1</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>40 072,4</td><td>25 675,6</td><td>14 396,8</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>51 759,1</td><td>33 597,6</td><td>18 161,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>52 444,0</td><td>33 345,7</td><td>19 098,3</td></tr>
</table></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2018 | 58 066,4 | 38 525,7 | 19 540,7 |
| 2019 | 55 841,4 | 35 773,6 | 20 067,8 |
| 2020 | 56 915,5 | 36 374,9 | 20 540,6 |
| 2021 | 58 008,3 | 36 984,4 | 21 0239 |
| Барлыгы | 437 007,0 | 285 879,3 | 151 127,7 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>6 нчы ярдәмче программаны тормышка ашыру 2021 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче аучылык ресурслары төрләренең гомуми санында аучылык ресурслары саны мониторингы алып барылган аучылык ресурслары төрләре өлешен 32 процентка кадәр арттырырга;<br>билгеле булган бозу фактларының гомуми санында федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге өлкәсендә билгеле булган, җаваплылыкка тарту турында карарлар чыгарылган бозулар өлешен 90 процент дәрәҗәсендә саклауны тәэмин итәргә;<br>аучылык биләмәләренең гомуми мәйданында хуҗалык эчендә аучылык чаралары үткәрелгән аучылык биләмәләре мәйданы өлешен 100 процентка кадәр арттырырга;<br>ташлап калдырылган тоту (аулау) коралларыннан ел саен чистартылган 878 кв.км акватория мәйданын тәэмин итәргә»;</td></tr>
</table>

II бүлектә:

унбишенче абзацта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 6 нчы ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 437 007,0 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән 285 879,3 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 151 127,7 мең сумы – билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет акчасы, шул исәптән:

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы |
|---|---|---|---|
| 2014 | 63 899,9 | 45 601,8 | 18 298,1 |
| 2015 | 40 072,4 | 25 675,6 | 14 396,8 |
| 2016 | 51 759,1 | 33 597,6 | 18 161,5 |
| 2017 | 52 444,0 | 33 345,7 | 19 098,3 |
| 2018 | 58 066,4 | 38 525,7 | 19 540,7 |
| 2019 | 55 841,4 | 35 773,6 | 20 067,8 |
| 2020 | 56 915,5 | 36 374,9 | 20 540,6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2021 | 58 008,3 | 36 984,4 | 21 0239 |
| Барлыгы | 437 007,0 | 285 879,3 | 151 127,7 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

6 нчы ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләренең эшчәнлеген яраштыру» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа исемендә «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге хезмәтләрнең эшчәнлеген яраштыру» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа) |
| Дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы |
| 7 нче ярдәмче программаның максаты | Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү |
| 7 нче ярдәмче программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитенә тискәре йогынты ясауны киметүне тәэмин итү, экология экспертизасы системасын камилләштерү, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны нормалаштыру, әйләнә-тирә мохитенең торышын мониторинглау.<br>2. Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларының дәүләт фондыннан рациональ файдалану һәм минераль-чимал базасын геологик өйрәнү һәм торгызу өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу.<br>3. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының табигать саклау законнары таләпләре үтәлешенә комплекслы төбәк дәүләт экология күзәтчелеген тәэмин итү.<br>4. Табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт функцияләрен нәтиҗәле тормышка ашыруны тәэмин итү |
| 7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру | 2014 – 2021 еллар |

<table>
<tr><td>вакытлары</td><td></td></tr>
<tr><td>7 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 713 135,3 мең сум* тәшкил итә.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Еллар</th><th>Барлык акча</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>183 317,7</td><td>183 317,7</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>232 804,6</td><td>232 804,6</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>226 556,8</td><td>226 556,8</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>250 609,3</td><td>250 609,3</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>223 722,7</td><td>223 722,7</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>191 927,0</td><td>191 927,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>197 634,1</td><td>197 634,1</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>203 563,1</td><td>203 563,1</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 713 135,3</td><td>1 713 135,3</td></tr>
</table>
* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Еллар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2017 елга төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның үткәрелмәгән конкурентлы ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлешен 13 процентка кадәр киметергә;<br>2021 елга:<br>экологияне нормалаштыру өлкәсендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны дәүләт җайга салуына кагылышлы әзерләнгән документлар санын 1040 данәгә кадәр арттырырга;<br>әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә хуҗалык яки башка эшчәнлекне, территорияне планлаштыруны һәм дәүләт экология экспертизасы үткәрүне планлаштырганда теркәлгән мөрәҗәгатьләр саны белән әзерләнгән килешүләр һәм үткәрелгән дәүләт экология экспертизалары саны чагыштырмасын 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итәргә;<br>стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми санында тотылган һәм зарарсызландырылган атмосфера һавасын пычраткыч матдәләр өлеше үсешен 60,6 процентка кадәр арттырырга;<br>тикшерелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр артык күп булган автотранспорт чаралары өлешен 11 процентка кадәр киметергә;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | су чыгаруның гомуми күләмендә пычранган (чистартылмаган) агыза торган сулар өлешен 11,5 процентка кадәр киметергә;<br>яңадан культивацияләнә торган җирләр өлешен 45 процентка кадәр арттырырга;<br>табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә билгеле булган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлешен 96 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>салынган штрафлардан алынган акча өлешен 70 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән «Гариза хәл ителгән» статусы бирелгән гаризалар өлешен 50 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Гариза хәл ителгән» статусы бирелгән һәм «Вакытында үтәлмәгән» статусы белән хәбәрнамәләр булмау;<br>җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру нәтиҗәсендә пычранган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданыннан төзекләндерелгән җир кишәрлекләре өлешен 85 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлешен кимендә 10 процент тәэмин итәргә;<br>тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробалары санын 35 180 данәгә кадәр арттырырга;<br>тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробаларына үткәрелгән лаборатория анализлары санын 64 480 данәгә арттырырга;<br>нефть скважиналарын эзләү-тикшерү һәм эксплуатация бораулавының планлаштырылган күләме үтәлешен 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>үткәрелгән дәүләт экспертизаларында геология разведкасы эшләренең нәтиҗәләре турында хисаплар әзерләүне 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>мөрәҗәгатьләрнең гомуми санында геологик мәгълүмат бирүгә канәгатьләндерелгән заявкалар санын 99 процентка кадәр арттырырга;<br>җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алуга каралган гаризалар санында бирелгән лицензияләр санын 96 процентка кадәр арттырырга;<br>Татарстан Республикасының гомумтаралган файдалы казылмалар запасларының еллык расланган балансын 1 баланс итеп (ел саен 2020 елга кадәр) тәэмин итәргә;<br>лицензиядә искәртелгән билгеле вакыйгалар килеп чыкканда, Россия Федерациясе территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган җир асты байлыклары участоклары яки |

| | |
|---|---|
| | җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары участокларыннан файдаланганда, Татарстан Республикасы бюджетына бер тапкыр түләнә торган түләүләр керүне 100 процентка кадәр тәэмин итәргә;<br>әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ регламентлары расланган дәүләт хезмәтләре һәм тикшерүдә тоту (күзәтчелек итү) буенча дәүләт функцияләре өлешен Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган мондый дәүләт хезмәтләренең (дәүләт функцияләренең) гомуми санында 100 процент дәрәҗәсендә саклап калырга;<br>Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләренең гомуми күләмендә аларның йөкләмәләре Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән контроль вакытларда 100 процент үтәлүен тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында һәм боерыкларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында әлеге норматив актлардагы шәхсиләштерелгән йөкләмәләре Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан 100 процент үтәлүен тәэмин итәргә;<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми күләмендә гражданнарның әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсенә караган, элегрәк язма җаваплар бирелгән язма яңадан кергән мөрәҗәгатьләре өлешен 0 процент дәрәҗәсендә сакларга;<br>әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итүгә дәүләт заказын 100 процент үтәүне тәэмин итәргә»; |

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. 7 нче ярдәмче программаның төп максаты, бурычлары, чаралары, көтелә торган төп соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Мәсьәләләрне анализлау нигезендә 7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру максаты булдырылды – әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

7 нче ярдәмче программа максатларына ирешү кысаларында табигатьне саклау өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге өлкәсендәге түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитенә тискәре йогынты ясауны киметүне тәэмин итү, экология экспертизасы системасын камилләштерү, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны нормалаштыру, әйләнә-тирә мохитенең торышын мониторинглау.

2. Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларының дәүләт фондыннан рациональ файдалану һәм минераль-чимал базасын геологик өйрәнү һәм торгызу өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу.

3. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының табигатьне саклау законнары таләпләре үтәлешенә комплекслы төбәк дәүләт экология күзәтчелеген тәэмин итү.

4. Табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт функцияләрен нәтиҗәле тормышка ашыруны тәэмин итү.

Беренче бурыч кысаларында түбәндәге чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

тискәре техноген йогынты ясауны чикләү өлешендә, шул исәптән калдыклар белән эш итү өлкәсендә рөхсәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны нормалаштыру, нормалаштыру өлкәсендә төбәк норматив хокукый актларын эшләү;

иң яхшы үтемле технологияләр һәм технологик нормалаштыру принципларына нигезләнгән әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны нормалаштыруның нәтиҗәле системасы эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектларын эшләү;

әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын яхшыртуга һәм экология иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр үткәрү, шул исәптән:

атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруларның стационар чыганакларының аерым төрләре өчен атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруларның техник нормативларын билгеләү буенча тәкъдимнәр эшләү;

продукцияне проектлаштыру, җитештерү, эксплуатацияләүгә тапшыру, эксплуатацияләү һәм утильләштерү процессларына карата экологик таләпләр билгеләү буенча тәкъдимнәр эшләү;

дәүләт экология экспертизасын үткәрү һәм аны үткәрү процедураларын камилләштерү;

әйләнә-тирә мохит торышын мониторинглау;

һава саклау эшчәнлеген, шул исәптән атмосфера һавасының сыйфатын исәпкә алу, бәяләү ысулларын һәм территорияне планлаштырганда һәм шәһәр төзелеше карарларын кабул иткәндә аңа үзгәреш керүне фаразлары ысулларын камилләштерү;

атмосфера һавасын, су объектларын һәм җир ресурсларын саклау чараларын тормышка ашыру, әйләнә-тирә мохите торышын мониторинглау;

хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә бозылган җирләрне торгызу һәм рекультивацияләү;

су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү, федераль милектә булган һәм республика территориясендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен судан файдалану шартнамәләре, су объектларын файдалануга бирү турындагы карарлар нигезендә бирү (Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычларыннан тыш);

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан төзелгән судан файдалану шартнамәләре буенча су объектларыннан файдаланган өчен түләүне администрлаштыру;

федераль милектә булган һәм республика территориясендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен судан файдалану шартнамәләре, су объектларын файдалануга бирү турындагы карарлар нигезендә бирү (Түбән Кама һәм Куйбышев сусаклагычларыннан тыш).

Беренче бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре:

экологияне нормалаштыру өлкәсендә әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауны дәүләт җайга салуына кагылышлы чыга торган документлар саны, данә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә хуҗалык яки башка эшчәнлекне, территорияне планлаштыруны һәм дәүләт экология экспертизасы үткәрүне планлаштырганда теркәлгән мөрәҗәгатьләр саны белән әзерләнгән килешүләр һәм үткәрелгән дәүләт экология экспертизалары саны чагыштырмасы, процент;

стационар чыганаклардан чыга торган пычраткыч матдәләрнең гомуми санында тотылган һәм зарарсызландырылган атмосфера һавасын пычраткыч матдәләр өлеше, процент;

тикшерелгән автомобильләрнең гомуми санында эшләп чыгарылган газларында пычраткыч матдәләр артык күп булган автотранспорт чаралары өлеше, процент;

су чыгаруның гомуми күләмендә пычранган (чистартылмаган) агыза торган сулар өлеше, процент;

яңадан культивацияләнә торган җирләр өлеше, процент.

Икенче бурыч кысаларында түбәндәге чараларны тормышка ашыру күздә тотыла:

1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучылар акчасы хисабына башкарыла торган геологик разведка эшләрен яраштыру һәм җайга салу түбәндәгеләрне үз эченә ала:

кыска, уртача һәм озак вакытка исәпләнгән чорларга Татарстан Республикасы нефть чыгару компанияләренең эксплуатация һәм эзләү-разведка бораулавының фаразланган күләмнәре турында тәкъдимнәр әзерләүне;

Татарстан Республикасы территориясендә федераль бюджет акчасы исәбеннән Россия Федерациясенең минераль-чимал базасын геологик өйрәнү һәм торгызу буенча дәүләт программаларында геологик разведка эшләре объектларын углеводород чималына кую буенча тәкъдимнәр әзерләүне;

Татарстан Республикасының нефть чыгару предприятиеләре буенча нефть чыгару, эксплуатация һәм эзләү-разведка бораулавы күләмнәре турындагы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыкларын әзерләүдә катнашу һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруны;

Татарстан Республикасы Хөкүмәте үткәрә торган киңәшмәләр өчен углеводород чималының ресурс базасы турында, нефть чыгару, эксплуатация һәм эзләү-разведка бораулавы күләмнәре турында мәгълүмат җыюны, аны гомумиләштерүне һәм анализлауны;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының дәүләт, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның төрле категорияләре һәм гражданнар мәнфәгатьләрендә геологик мәгълүматны файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү эшчәнлегенә мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтүне;

сайттан файланучыларга Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын өйрәнү, торгызу, файдалану һәм саклау турында мәгълүмат бирү өлешендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының интернет-сайтын алып баруны.

2. Гомумтаралган файдалы казылмаларның табылган запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү, кондицияләрне техник-икътисадый нигезләү һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары участоклары турында геологик мәгълүмат бирү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкаруга башка проект документларын килештерүдә катнашуны;

Татарстан Республикасы гомумтаралган файдалы казылмаларының минераль-чимал базасын заманча бәяләү һәм гомумтаралган файдалы казылмаларның минераль-чимал базасын өлешчә төзелгән ятмалары запасларын яңадан исәпләүне;

гомумтаралган файдалы казылмаларның минераль-чимал базасының микъдари күрсәткечләренең хәзерге торышын бәяләүне;

Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының бүленмәгән фондына кайбер ятмаларның калган запасларын күчерү буенча тәкъдимнәр әзерләүне һәм Запаслар буенча республика комиссиясендә карап тикшерүне (хәзерге вакытта гамәлдә булмаган яки банкротлык процедурасын үткән оешмаларда булган җир асты байлыкларын эшкәртү хокукына лицензияләр нигезендә мәгълүмат балансыннан чыгару);

кайбер ятмаларның калган запасларын ачыклауны.

3. Җир асты байлыкларыннан файдалануны мәгълүмати тәэмин итү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

җир асты байлыкларыннан файдалануны мәгълүмати тәэмин итүне, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына бирелгән лицензияләрне һәм башкарылган геологик разведка эшләрен исәпкә алуны;

гамәлдәге һәм элек бирелгән лицензияләр буенча мәгълүматларның фактографик базасын алып баруны;

«Җир асты байлыклары» геомәгълүмат системасының федераль программасы комплексын алып баруны;

геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча территориаль саклагычларда тупланган дәүләт геологик мәгълүмат ресурсларын формалаштыруны, алып баруны һәм алардан файдалануны оештыруны;

геологик хисапларны һәм картографик материалларны кабул итүне, саклауны һәм системалаштыруны;

геологик яктан өйрәнгәнлекнең исәпкә алу карталарын һәм картограммаларын төзүне;

кулланучылар соравы буенча геологик мәгълүмат бирүне;

оешмалар һәм хуҗалык эшчәнлеге субъектлары тарафыннан расланган программалар буенча геологик мохитне мониторинглау эшен алып баруга инструктив-методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыруны;

җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яки аның территориаль органнары тарафыннан төзелә торган конкурс яки аукцион комиссияләре эшендә билгеләнгән тәртиптә катнашуны;

җир асты байлыкларыннан файдаланучылар акчасы исәбеннән башкарыла торган геологик разведка эшләрен яраштыруны һәм җайга салуны;

гомумтаралган файдалы казылмалар разведкалау һәм чыгару яки геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары участокларында яки җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары участокларында гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару өчен Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукын бирүгә аукционнар әзерләүне һәм үткәрүне.

4. Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фондын лицензияләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

җир асты байлыкларының бүленмәгән фонды объектларын лицензияләүгә һәм үзләштерүгә әзерләнүне;

гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен

җирле әһәмияттәге кишәрлекләрнең җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү системасы нигезендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен, шул исәптән файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары участокларын исәпкә алуны;

җир асты байлыклары участокларыннан файдалану хокукына бирелгән лицензияләрне исәпкә алуны;

табигый, экологик һәм инфраструктура сәбәпләре аркасында эшкәртелә алмаган запасларны дәүләт балансыннан төшерүне;

Татарстан Республикасы гомумтаралган файдалы казылмалары запасларының территориаль балансын төзүне.

Икенче бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре (индикаторлары) булып түбәндәгеләр тора:

нефть скважиналарын эксплуатация бораулавы буенча факттагы күләмнең планлаштырылган күләмгә карата чагыштырмасы, процент;

нефть скважиналарын эзләү-тикшеренү бораулавы буенча факттагы күләмнең планлаштырылган күләмгә карата чагыштырмасы, процент;

геологик разведка эшләре нәтиҗәләре турындагы хисаплар саны һәм үткәрелгән дәүләт экспертизалары саны нисбәте, процент;

мөрәҗәгатьләрнең гомуми санына карата геологик мәгълүмат бирүгә канәгатьләндерелгән заявкалар саны чагыштармасы, процент;

геологик өйрәнү, тикшерену һәм файдалы казылмалар чыгару максаты белән җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы алуга карап тикшерелгән гаризалар санына карата бирелгән лицензияләр саны чагыштырмасы, процент;

расланган план мәгънәләренә карата лицензиядә искәртелгән билгеле вакыйгалар килеп чыкканда, Россия Федерациясе территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар булган җир асты байлыклары участоклары яки җирле әһәмияттәге участоклар буенча җир асты байлыкларыннан файдаланганда, җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бер тапкыр түләнә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы бюджетына фактта кертелү күләме чагыштырмасы, процент;

Татарстан Республикасының гомумтаралган файдалы казылмалары запасларының еллык расланган балансы, 1 баланс.

Өченче бурыч кысаларында комплекслы дәүләт экология күзәтчелеген, шулай ук атмосфера һавасын саклау, су объектларын саклау, җир ресурсларын саклау һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә комплекслы дәүләт экология күзәтчелеген матди-техник тәэмин итү буенча чаралар үткәрү, шулай ук республика дәүләт экология күзәтчелеген лаборатор-аналитик яктан тәэмин итү күздә тотыла.

Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык итүче субъектларга тикшерүләр үткәрү оештырыла.

Өченче бурычларны хәл итүнең төп күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә билгеле булган бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше, процент;

салынган штрафлардан алынган акча өлеше, процент;

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына кергән, «Гариза хәл ителгән» статусы бирелгән гаризалар өлеше, процент;

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында «Вакытында үтәлмәгән» статусы белән хәбәрнамәләр булу, берәмлек;

җитештерү һәм куллану калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру нәтиҗәсендә пычранган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданыннан төзекләндерелгән җир кишәрлекләре өлеше, процент;

төбәк дәүләт экология күзәтчелеге нәтиҗәлелеге, мең сум;

административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлеше, процент;

риск-юнәлеш бирү алымын исәпкә алып, чираттагы елга тикшерүләр планын формалаштыру, әйе/юк;

тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробалары саны, данә;

тышкы мохитнең (су, һава һәм туфрак) сайлап алынган пробаларына үткәрелгән лаборатория анализлары саны, данә.

Дүртенче бурыч кысаларында дәүләт функцияләрен һәм дәүләт хезмәтләрен регламентлаштыру, аларны электрон рәвештә гамәлгә ашыруга күчү, электрон документлар әйләнешен кертү чараларын, кадрлар сәясәтен нәтиҗәле үткәрүгә юнәлдерелгән чараларны үтәү, Программаның куелган максатлары һәм бурычлары кысаларында дәүләт хезмәте кадрларының үсешен тәэмин итү карала. Шулай ук бу бурыч белән әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә табигать саклау чараларына төрле чыганаклардан финанс чараларын җәлеп итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру, дәүләт заказлары буенча конкурс

торглары процедураларын үткәрү, табигатьне саклау һәм геологик чараларны тормышка ашыру, финанс ярдәме күрсәтү, акчаны максатчан файдалануны, бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген тикшерүдә тоту күздә тотыла.

Дүртенче мәсьәләне хәл итүнең төп күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт хезмәтләренең сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсе, процент;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары тарафыннан алар өчен үтәү вакыты билгеләнгән йөкләмәләрнең гомуми күләмендә әлеге затларның Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән контроль вакытларда башкарылган йөкләмәләре өлеше, процент;

Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында һәм боерыкларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында әлеге норматив актларда бирелгән һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан башкарылган шәхсиләштерелгән йөкләмәләр өлеше, процент;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренең гомуми күләмендә гражданнарның әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсенә караган, элегрәк язма җаваплар бирелгән язма яңадан кергән мөрәҗәгатьләре өлеше;

регламентта каралган вакытларда килештерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары проектлары өлеше, процент;

билгеләнгән регламент вакытларында Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары проектларының әлеге норматив хокукый актларның гомуми күләмендәге өлеше, процент;

төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның үткәрелмәгән конкурентлы ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлеше, процент;

сатып алуларның еллык җыелма күләменнән кече эшмәкәрлек субъектларында һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларда урнаштырылган сатып алулар өлеше, процент;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен үтәү, процент;

бер кешегә исәпләгәндә әйләнә-тирә мохитне саклауга, табигать ресурсларын торгызуга һәм файдалануга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнары, сум.

7 нче ярдәмче программаның максатлары, бурычлары һәм чаралары яктылыгында 7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында җентекле мәгълүмат аңа теркәлгән кушымтада бирелә.

7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2021 еллар.»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 7 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 713 135,3 мең сум* тәшкил итә.

(мең сум)

| Еллар | Акча, барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|
| 2014 | 183 317,7 | 183 317,7 |
| 2015 | 232 804,6 | 232 804,6 |
| 2016 | 226 556,8 | 226 556,8 |
| 2017 | 250 609,3 | 250 609,3 |
| 2018 | 223 722,7 | 223 722,7 |
| 2019 | 191 927,0 | 191 927,0 |
| 2020 | 197 634,1 | 197 634,1 |
| 2021 | 203 563,1 | 203 563,1 |
| Барлыгы | 1 713 135,3 | 1 713 135,3 |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

7 нче ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аларны капиталь ремонтлау» ярдәмче программасында (алга таба – 8 нче ярдәмче программа):

8 нче ярдәмче программа исемендә «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программа исеме» юлында «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

«8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты» юлында «2015» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

II бүлекнең сигезенче абзацында «2015» саннарын «2021» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин